Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел №241

Әлмәт муниципаль районы тарафыннан аерым мәсьәләләрне чишү буенча авыл җирлекләренең өлешчә вәкаләтен кабул итүе турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль законның 15 маддәсенең 4 өлешенә, Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә булучы, Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнарының авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән килешү төзү тәртибе турында өлешчә вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) турында» №468 карарына туры китереп,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы составына керүче Габдрахман, Аппак, Әлмәт, Бишмунча, Бота, Борискино, Баграж-Нипольск, Васильевка, Югары Акташ, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кәләй, Колшәрип, Кама-Исмәгыйль, Кичү, Кичүчат, Клементейкино, Кузайкино, Урман-Кәләе, Миңлебай, Мәмәт, Түбән Абдул, Түбән Мактама, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Яңа Никольский, Яңа Троицкий, Рус Акташы, Иске Михайловка, Сәрән, Сөләй, Иске Суркино, Ямаши, Ямаш, Тайсуган җирлекләре Советларының башкарма комитетларының вәкаләтләрен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

- җирлекнең муниципаль милкендә булган милек белән идарә итү;
- җирлекнең муниципаль милке реестрын алып бару

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Әлмәт муниципаль районы составына кергән җирлекләрнең башкарма комитеты белән җирлекләр бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына, җирлекләрнең башкарма комитетларының өлешчә вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) килешүе тәртибенә (1нче кушымта) тәңгәл китереп,бюджетара трансферт исәбенә аларның өлешчә вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә;

- авыллар бюджетыннан район бюджетына бюджетара трансфертны тапшыру тәртибе я бүлү методына туры китереп бюджетара трансфертның күләмен билгеләргә;

- әлеге карарны тормышка ашыру максатыннан 2018 ел, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының

бюджеты турындагы карарына үзгәртүләр кертү турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының карар проектын законнар чыгару җыелмасына туры китереп эшләргә һәм тәкъдим итәргә.

3. Әлмәт муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары көчләрен югалткан дип санарга:

- 2015 елның 6 маенда кабул ителгән 469 нчы санлы “Әлмәт муниципаль районына авыл җирлекләре башкарма комитетларының җирле әһәмияткә ия аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча өлешчә вәкаләтен тапшыру турында”

- 2015 елның 16 июнендә кабул ителгән 478 нчы санлы “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маенда кабул ителгән 469 нчы санлы “Әлмәт муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларының җирле әһәмияткә ия аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча өлешчә вәкаләтен тапшыру турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында”;

- 2015 елның 16 июнендә кабул ителгән 477 нче санлы “Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсенең җирле әһәмияткә ия аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча өлешчә вәкаләтен тапшыру турында”;

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ф.Х. Шәйхулова) әлеге карарны «Әлмәт хәбәрләре» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының закон, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (И. Р. Бәһманов) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2018 елның
11 маендагы 241 нче
карарына 1 нче кушымта

Килешү

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына
Әлмәт муниципаль районының _____________________авыл җирлеге
башкарма комитетының җирле урыннар өчен әһәмиятле булган аерым
мәсьәләләрне чишү буенча өлешчә вәкаләтен тапшыруы турында

“____”_______________2018 ел ___________________________
(авыл, шәһәр һ.б.)

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе ____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме күрсәтелә)
йөзеннән, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты турындагы кагыйдәсе һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче, алга таба “Район Башкарма комитеты”, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ______________________________җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме күрсәтелә)
________________ йөзеннән,Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ____________________________ җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ___________________________ җирлегенең башкарма комитеты кагыйдәсе, алга таба, “Җирлекнең башкарма комитеты”, икенче яктан, икесе бергә, “Яклар”, түбәндәге Килешү төзеделәр:

1. Килешү предметы

Әлеге килешүнең предметы булып җирлек Башкарма комитетының Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына җирле урыннар өчен әһәмиятле булган аерым мәсьәләләрне чишү буенча өлешчә вәкаләтен тапшыруы:

- җирлекнең муниципаль хосусый милкендә булган милек белән идарә итү;
- җирлекнең муниципаль хосусый милкенә реестр кертү.

2. Якларның хокуклары һәм вазифалары

2.1.Авыл җирлеге башкарма комитеты Район башкарма комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

- әлеге Килешү (алга таба – вәкаләтләр) нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәк булган финанс чаралары һәм матди ресурслар;
- вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2.Җирлек башкарма комитеты хокуклары:

- Район башкарма комитеты вәкаләтләрен, тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны әлеге Килешүнең 5.1 – 5.3 пунктлары билгеләгән тәртиптә максатчан тотылуын контрольдә тоту;

- Район Башкарма комитетыннан әлеге Килешүгә кагылышлы мәгълүматны алу.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлары:

- вәкаләтләрне закон таләпләре нигезендә башкарырга, шул исәптән тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны вәкаләтләрне үтәүгә максатчан кулланылуын тәэмин итәргә;

- Җирлек Башкарма комитетына квартал саен вәкаләтләрне башкару хакында, шулай ук аерым сораулар буенча башка мәгълүматларны да күрсәтергә.

2.4. Район Башкарма комитеты хокуклары:

- Авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрне үтәү өчен тапшырган финанс чараларын һәм матди ресурсларны кабул итү һәм куллану;

- Авыл җирлеге Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мәгълүматны сорату;

- вәкаләтләрне башкару максатыннан өстәмә финанс чаралары һәм матди ресурслардан закон кысаларында файдалану.

## 3. Вәкаләтләрне башкару өчен матди чараларны бирү тәртибе

3.1.Вәкаләтләрне башкару өчен кирәк булган финанс чаралары бюджетара трансферт рәвешендә кабул ителгән закон нигезендә күчерелә.

3.2. Вәкаләтләрне башкару өчен кирәк булган финанс чараларының күләме Әлмәт муниципаль районы Советының киләсе финанс елына һәм план чорына кабул иткән район бюджеты карары нигезендә билгеләнә.

3.3. Вәкаләтләрне башкару өчен кирәк булган финанс чаралары квартал саен тигез өлешләрдә күчерелә.

3.4. Район Башкарма комитеты финанс чаралардан максатчан файдаланмаган очракта ун көн эчендә алар җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 4. Материаль ресурсларны тапшыру тәртибе

4.1. Вәкаләтләрне башкару өчен Район башкарма комитеты Район Советы карары нигезендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль Законның 35 маддәнең 10 өлеше 5 пункты нигезендә әлеге Килешүгә кул куйганнан утыз көн эчендә кабул итә, ә җирлек Башкарма комитеты Килешү нигезендә каралган финанс чараларын һәм матди ресурсларны тапшыра.

4.2. Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән бушлай файдалану мөмкинлеге әлеге Килешү гамәлдә булу срогына каралган.

4.3. Килешүнең 4.1 пунты нигезендә тапшырылган материаль ресурсларны куллану тәртибе бушлай файдалану мөмкинлеге турындагы килешү белән билгеләнә һәм аның мөһим шарты булып тора.

## 5. Вәкаләтләрне башкаруга контроль

5.1. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләрне башкаруга тикшерү үткәрә, Район Башкарма комитетынннан тапшырылган финанс чаралардан һәм матди ресурслардан файдалану буенча кирәкле мәгълүматларны соратып ала. Район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитеты соравы буенча соралган мәгълүматларны бирергә һәм тикшерелә торган объектларга эләгү мөмкинлеген оештырырга тиеш.

5.2. Отчет формасы һәм аны бирү тәртибе район Башкарма комитеты хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чаралары һәм матди ресурслардан файдалануга контроль Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Контроль-хисап палатасы һәм Район Башкарма комитеты тарафыннан, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты соратуы буенча башкарыла.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу срогы

6.1. Килешү Якларның кул кую көненнән гамәлгә керә һәм 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешү 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Якларның берсе дә әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган Килешү срогы чыгарга 30 көн алда Килешүне таркату тәкъдиме белән чыкмаса, Килешү алдагы финанс елына озайтылган исәпләнә.

## 7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге Килешүне туктату түбәндәге очракларда мөмкин:

- якларның килешүе буенча;
- берьяклы рәвештә, Якларның йөкләмәләрен үтәмәү яки тиешенчә башкармау очрагында.

7.2. Әлеге Килешүне таркату турындагы язу каршы Як тарафыннан язмача фаразланган туктату срогыннан 30 көн алда җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешүне вакытыннан алда таркату очрагында Район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне башкару өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны кайтара.

## 8.Якларның җаваплылыгы

8.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яки тиешенчә башкармау закон тарафыннан каралган җавапка тарту өчен нигез булырга мөмкин.

8.2. Бер якның Килешү белән каралган бурычларын үтәмәгән очракта гаепле Як каршы Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чараларының 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

8.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүдән азат итми.

9. Бәхәсләрне чишү тәртибе

Әлеге Килешү буенча туган бәхәсләр сөйләшү һәм башка төр килешү процедуралары юлы белән хәл ителә.

Бәхәсләрне сөйләшү һәм башка төр килешү процедуралары юлы белән хәл итәргә мөмкин булмаган очракта закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә карала.

10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара килешүе нәтиҗәсендә һәм язмача өстәмә килешү кертеп теркәлә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү һәр Як өчен тигез юридик хокулы ике экземплярда төзелгән.

11. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Әлмәт муниципаль районы<br>Башкарма комитеты<br>җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Әлмәт муниципаль районы<br>_____________ авыл җирлеге<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| _______________ ________ | _______________ ______________ |

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин